СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с. Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru


**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Апаз авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**“ 27 ” октябрь 2025 ел** **№ 6**

**Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Мирҗәм авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар чыгарды:

1.Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Мирҗәм авылында Мирҗәм авылы, Н.Сафин урамы, 36 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 11 ноябренә 19 сәгать 00 минутта халык җыенының билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:
«2026 елда Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Мирҗәм авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 600 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, түләү күләме 1200 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу; Н.Сафин, Мәскәү , Профсоюз урамнарында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (буа ясау һәм тирә-як территориясен төзекләндерү (шул исәптән койма төзелеше, төзелеш материаллары сатып алу, яктырту эшләре (шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, сатып алу һәм урнаштыру)) дүртенче этабы)»?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

3. Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Мирҗәм авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Апаз авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Мирҗәм авылы, Н.Сафин урамы, 36 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов

СОВЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ